| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

01.08.2024 Олы Кайбыч ав. № 278

«2022 - 2025 елларга Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру» муниципаль программасын раслау турында» Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 28 апрелендәге 217 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«2022 - 2025 елларга Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру» муниципаль программасы чараларын нәтиҗәле гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. «2022 - 2025 елларга Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру» муниципаль программасын раслау турында» Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 28 апрелендәге 217 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«2022 - 2025 елларга Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру» муниципаль программасына кушымтаны түбәндәге эчтәлекле юллар белән тулыландырырга:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 1 | «Милләткә, телгә, дини инануларга бәйсез рәвештә гражданнарның тигез хокуклылыгын бозу фактлары турында гражданнар мөрәҗәгатьләрен мониторинглау, шулай ук эшкә алганда, кадрлар резервын рәсмиләштергәндә башка хәлләр турында | Ел саен | Район Советы, Башкарма комитет | - |
| 2 | Массакүләм мәгълүмат чаралары һәм миграция проблемалары буенча социаль челтәрләр мониторингы үткәрү | Ел саен | Район Советы, Башкарма комитет | - |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 3 | «Кайбыч таңнары» район газетасында рухи-әхлакый кыйммәтләрне, милләтара һәм динара ихтирам һәм үзара ярдәмне пропагандалаучы материалларны системалы бастырып чыгаруны оештыру | 2024-2025 еллар | Район Советы, Башкарма комитет, «Кайбыч таңнары» газетасы баш мөхәррире (килешү буенча) | - |

2. Финанс-бюджет палатасына ел саен район бюджетын формалаштырганда, чираттагы елга, район бюджетыннан шул максатларга юнәлтелгән чаралар чикләрендә мөмкинлекләрне исәпкә алып, 2024-2025 елларга программа чараларын гамәлгә ашыруга акча бүлеп бирүне күздә тоту каралган.а.

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http:/ kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга һәм http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның гамәлгә ашырылуын тикшереп торуны Башкарма комитет Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Ф.Ф.Петуховага йөкләргә.

Җитәкче А.Н. Макаров